# Габдулла Тукай
# “Кошчык”







*Кичә мин читлек ачтым, андагы кошчыкны коткардым,*
*Күңелсез тоткынымны киң яшел урманга кайтардым.*

www.DesktopCollector.com

*Аңар бирдем азатлык мин, үземдә*
*шул вакыт күрдем:*
*Тынычлап калды никтер һәм*
*тәмам иркенләде күңлем.*




Күзем белән озаттым: кошчыгым
урман таба очты,
Югалды күк йөзендә тиз вакытта, бер
дә юк төсле.


Очып киткәндә ул шундый
матурлап сайрады моңлы:
Миңа, санки, азат иткән өчен
изге дога кылды.
WWW.GEE.RU